II ТАТАР ҖЫРЫ ФЕСТИВАЛЕ

# ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ

**ВЕТЕР ПЕРЕМЕН**

**II ФЕСТИВАЛЬ ТАТАРСКОЙ ПЕСНИ**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы
*Министерство культуры Республики Татарстан*

Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры
*Татарский академический государственный театр оперы и балета им.М.Джалиля*

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмендә
*При поддержке Президента Республики Татарстан*

# ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ

**ВЕТЕР ПЕРЕМЕН**

**II ТАТАР ҖЫРЫ ФЕСТИВАЛЕ**

*II ФЕСТИВАЛЬ ТАТАРСКОЙ ПЕСНИ*

**1, 2, 3 декабрь 2017**
**Казан**

*1, 2, 3 декабря 2017*
*Казань*

# ПРОЕКТНЫ ЭШЛӘДЕЛӘР
## /НАД ПРОЕКТОМ РАБОТАЛИ/

Музыкаль җитәкче – **ВАДИМ ЭЙЛЕНКРИГ** (Мәскәү)
Куючы режиссер – **ЮРИЙ АЛЕКСАНДРОВ** (Санкт-Петербург)
Куючы рәссам – **ВИКТОР ГЕРАСИМЕНКО** (Мәскәү)
Проект стилисты – «VIP GROUP KAZAN»
Дирижер – **СТАНИСЛАВ КУРБАЦКИЙ** (Мәскәү)
Вокал буенча педагоглар – **ВЕНЕРА ГАНИЕВА, КСЕНИЯ** һәм **АЛЕКСЕЙ КОРОБКОВЛАР** (Мәскәү)
**СЕРГЕЙ МАНДРИК** җитәкчелегендәге **«STREET JAZZ»** балеты (Мәскәү)
Компьютер графикасы – **ДАНИЛ ГЕРАСИМЕНКО** (Мәскәү)
Ут куючы рәссам – **ИВАН ВИНОГРАДОВ** (Мәскәү)
Тавыш режиссерлары – **ВЛАДИМИР ОВЧИННИКОВ** (Мәскәү), **КАМИЛ ФӘЙЗРАХМАНОВ**
Башкаручы продюсер – **ТАТЬЯНА ШАХНИНА**
Генераль продюсер – **РӘҮФӘЛ МӨХӘММӘТҖАНОВ**

Музыкальный руководитель – **ВАДИМ ЭЙЛЕНКРИГ** (Москва)
Режиссер-постановщик – **ЮРИЙ АЛЕКСАНДРОВ** (Санкт-Петербург)
Художник-постановщик – **ВИКТОР ГЕРАСИМЕНКО** (Москва)
Стилист проекта – «VIP GROUP KAZAN»
Дирижер – **СТАНИСЛАВ КУРБАЦКИЙ** (Москва)
Педагоги по вокалу – **ВЕНЕРА ГАНЕЕВА, АЛЕКСЕЙ** и **КСЕНИЯ КОРОБКОВЫ** (Москва)
Балет **«STREET JAZZ»** под руководством **СЕРГЕЯ МАНДРИКА** (Москва)
Компьютерная графика – **ДАНИЛ ГЕРАСИМЕНКО** (Москва)
Художник по свету – **ИВАН ВИНОГРАДОВ** (Москва)
Звукорежиссеры – **ВЛАДИМИР ОВЧИННИКОВ** (Москва), **КАМИЛЬ ФАЙЗРАХМАНОВ**
Исполнительный продюсер – **ТАТЬЯНА ШАХНИНА**
Генеральный продюсер – **РАУФАЛЬ МУХАМЕТЗЯНОВ**

# КАТНАШУЧЫЛАР
## / УЧАСТНИКИ /

| | |
|---|---|
| **«Jukebox trio»** | **«Jukebox trio»** |
| **Lucy Campeti** | **Lucy Campeti** |
| **Әмир Әхмәдишин** | **Амир Ахмадишин** |
| **Марсель Вагыйзов** | **Марсель Вагизов** |
| **Зәринә Вилданова** | **Зарина Вильданова** |
| **Лилиана Газизова** | **Лилиана Газизова** |
| **Айгөл Гардисламова** | **Айгуль Гардисламова** |
| **Ильвина** | **Ильвина** |
| **Лилиана Ирназарова** | **Лилиана Ирназарова** |
| **Артур Исламов** | **Артур Исламов** |
| **Эльза Исламова** | **Эльза Исламова** |
| **Ксения Коробкова** | **Ксения Коробкова** |
| **Мәликә** | **Малика** |
| **Ләйсән Мингазова** | **Ляйсан Мингазова** |
| **Салават Миңнеханов** | **Салават Минниханов** |
| **Илнар Миранов** | **Ильнар Миранов** |
| **Әлфия Нигъмәтуллина** | **Альфия Нигматуллина** |
| **Румия Ниязова** | **Румия Ниязова** |
| **Ильмир Сагадиев** | **Ильмир Сагадиев** |
| **Айдар Сөләйманов** | **Айдар Сулейманов** |
| **Раяз Фасыйхов** | **Раяз Фасихов** |
| **Илгиз Шәйхразиев** | **Ильгиз Шайхразиев** |
| **Алинә Шәрипҗанова** | **Алина Шарипжанова** |
| **Макъсуд Юлдашев** | **Максуд Юлдашев** |
| **«Ямьле»** | **«Ямьле»** |

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ СӘЛАМЛӘВЕ

## ПРИВЕТСТВИЕ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН



**Кадерле дуслар!**

«Үзгәреш җиле» икенче татар җыры фестивалендә катнашучыларга, аны оештыручыларга, тамашачыларга ихлас күңелдән сәламнәремне җиткерәм.

Бер ел элек уздырылган һәм зур уңыш казанган беренче фестиваль татар халык җырлары һәм татар эстрада җырларының милли тәңгәллекләрен саклаган хәлдә, заманча яңгырый алуына, төрле милләт вәкилләренә, яшьләргә дә, өлкәннәргә дә ошавына дәлил булды.

Безнең алда яңа үрләр, яңа бурычлар тора: татар эстрадасының, заманча музыкада, лаеклы сәхнә эшләнешендә гәүдәләнеш алып, халыкара мәйданга чыгасына шигем юк.

Әлеге иҗади проектны гамәлгә ашыруда көч куйган һәркемгә игелекле хезмәтләре өчен рәхмәт белдерәм. «Үзгәреш җиле»ндә катнашучыларга илһамлы иҗат, ә тамашачыларга онытылмас якты тәэсирләр телим.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

**Дорогие друзья!**

Приветствую зрителей, участников и организаторов II фестиваля татарской песни «Үзгәреш җиле».

Первый фестиваль, с успехом проведенный год назад, стал убедительным доказательством того, что татарская эстрадная и народная песня, не теряя своей идентичности, может звучать современно, быть интересной слушателям разных национальностей и возрастов.

Впереди — новые задачи и новые высоты: мы уверены, что татарская эстрада, обретя актуальное музыкально-сценическое воплощение, может быть востребована на международной арене.

Благодарю всех создателей этого творческого проекта за проделанную работу. Желаю участникам вдохновения, а зрителям — ярких и незабываемых впечатлений.

**Президент Республики Татарстан** **Р. Н. Минниханов**

# «ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ» ҺӘМ ТРАДИЦИЯ МАЯКЛАРЫ

## «ВЕТЕР ПЕРЕМЕН» И МАЯКИ ТРАДИЦИЙ

**ВАДИМ ДУЛАТ-АЛЕЕВ**
**Сәнгать фәннәре докторы, профессор, ТР атказанган сәнгать эшлеклесе**
*ATI-TIMES.RU*

...Әлеге проект, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов инициативасы белән, безнең эстрадага «ниндидер үзгәреш кертергә тырышу» идеясен тормышка ашыру ниятеннән башланып китте. Әгәр дә инде куелган сораугa әйләнеп кайтсак, проблема татар музыка сәнгатенең бүгенге дәрәҗәсендә, аның «конвертацияләнү сәләтендә» (бөтенроссия, Евразия, дөнья югарылыгына); «Үзгәреш жиле» («Ветер перемен») Татар җыры фестивале исемен алган проект – проблеманы хәл итү юлында ясалган беренче адым. Президент фестивальнең беренче концертында ук «дәвамы, һичшиксез, булачагын» әйтте...

Опера театры сәхнәсенә гүзәл чәчәк урнаштырылган. Ул сәхнәне яулап алган, диярсең. Җырның рухына карап, ул формасын һәм төсен үзгәртә; ябыла һәм кабат ачыла; йә гөмбәзгә, йә чатырга, йә чынаяк яки казанга, йә ялкын телләренә, йә янган йөрәккә, йә «Аватар» стилендәге якты урманга әверелә. Фестиваль

---

** «Үзгәреш җиле» фестивале беренче тапкыр 2016 елның 5-6 ноябрендә Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә үтте, 2016 елның 4 декабрендә проект Мәскәүдә тәкъдим ителде. Проект турында массакүләм матбугат чараларында басылган язмаларның (рецензияләр) өзекләре матбугатка күзәтү рәвешендә бирелә.*

**ВАДИМ ДУЛАТ-АЛЕЕВ**
**Доктор искусствоведения, профессор, заслуженный деятель искусств РТ**
*ATI-TIMES.RU*

...Этот проект возник по инициативе Президента Республики Татарстан Рустама Минниханова как воплощение идеи «попытаться что-то изменить» в нашей эстраде. Если вернуться к вопросу, как он был поставлен, то проблема – это современный уровень татарского музыкального искусства, его «конвертируемость» (всероссийская, евразийская, мировая и др.); а конкретный первый шаг на пути решения проблемы – проект, получивший название Фестиваль татарской песни «Ветер перемен» («Узгэреш жиле»). Уже на первом концерте фестиваля Президент сказал, что «продолжение обязательно будет»...
На сцене оперного театра расцвел цветок. Он заполнил почти все пространство сцены. Следуя за настроением песни, менял форму и переливался всеми цветами; закрывался и раскрывался вновь; превращался то в купол, то в шатер, то в чашу или казан, то в лепестки пламени, то в пылающее сердце, то в светящийся лес в стиле «Аватара». Эта эксклюзивная

---

** Впервые фестиваль «Узгэреш жиле» состоялся 5-6 ноября 2016 года на сцене ТАГТОиБ им.М.Джалиля, 4 декабря 2016 года проект был представлен в Москве. Отзывы о проекте в средствах массовой информации (рецензии) приводятся фрагментарно (цитаты, выдержки) и представляют собой обзор печати.*













өчен махсус ясалган бу эксклюзив конструкциянең потенциалы зур, мөгаен, ул сәхнәдә тагын да кулланылыр, хәтта символик мәгънә алыр – моның өчен аның бөтен сыйфатлары да бар – интернациональ универсаль мәгънәгә һәм традицион татар символикасына ия. Ул гаҗәеп матур һәм… функциональ иде. Мәскәү рәссамы Виктор Герасименконың Казан эше, ут буенча рәссам Иван Виноградовның хезмәтен дә искә алып, тора-бара сценография буенча кулланмаларга керер дип уйлыйм.

Концерт башлануы Александр Ключаревның «Республикам минем – Татарстан» җырындагы таныш фанфарлар белән хәбәр ителде – алар күп еллар дәвамында татар радиосының чакыру сигналы булып тора. Әлеге авазлар аша залга тарих керде диярсең – бу гадәти булмаган XX тарихы – татар мәдәнияте өчен «үзгәрешләр гасыры», яңа мөмкинлекләр һәм яңа казанышлар чоры. «Республикам минем – Татарстан» җыры тулысы белән бөтен катнашучылар башкаруында финалда яңгырады һәм фестивальнең гимнына әверелде. Концерт программасында таныш халык җырларының билгесезлектә калган авторлары, классиклар һәм замандашлар берләште.

Бу бик зур әһәмияткә ия! Милли мәдәниятне читтә тәкъдим итү бурычы тора икән – вакларга кирәкми. Татар мәдәнияте аның белән беренче тапкыр танышучылар өчен бербөтен кристалл булып күренергә тиеш, очкыннарының төрле төсмерләре – алары эчтәрәк.

…Программадагы исемнәр – Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Хәсән Туфан, Һади Такташ, Зәһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Ерикәй, Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйпов, Илдар Юзеев һәм башкалар – XX гасыр татар

конструкция, разработанная специально для фестиваля, далеко не исчерпала свой потенциал и, вероятно, еще послужит нашей сцене, а может быть, даже станет символической – она обладает всеми необходимыми качествами, в том числе интернациональной универсальностью семантики и связями с традиционной татарской символикой. Это было красиво и… функционально. Думаю, что эта казанская работа московского художника Виктора Герасименко, на которую ориентировался и художник по свету Иван Виноградов, со временем попадет в учебные пособия по сценографии.

О начале концерта возвестили знаменитые фанфары из песни Александра Ключарева «Моя Родина – Татарстан», они много лет были позывными на татарском радио. И вместе с ними в зал словно вошла история – весь очень непростой XX век, который был «веком перемен», веком новых возможностей и новых достижений для татарской культуры. Полностью песня «Моя Родина – Татарстан» в исполнении всех участников концерта прозвучала в финале и стала гимном фестиваля. В программе концерта объединились неизвестные авторы известных народных песен, классики и современники. Это важно! Если стоит задача представить национальную культуру вовне, то дробить ее не надо. Татарская культура для встречающихся с ней впервые должна выглядеть единым кристаллом, а все многообразные оттенки переливающихся искр – это уже внутри него.

…Встречающиеся в программе имена – Салих Сайдашев, Назиб Жиганов, Хасан Туфан, Хади Такташ, Загид Хабибуллин, Джаудат Файзи, Наки Исанбет, Ахмет Ерикей, Рустем Яхин, Алмаз Монасыпов, Ильдар Юзеев и другие – это классика татарской культуры XX века, которая






мәдәнияте классикасы, алар XXI гасырда да җанлы традиция булып калырга тиешләр. Музыканы остазлардан түгел, бүгенге авазлар яңгырашы аша өйрәнүчеләр өчен классиканың «эфирда» яңгыравы шарт, аның яңача башкаруда һәм сыйфатлы язмада булуы хәерле. Сәнгатьнең агарту, тәрбияләү һәм берләштеру функциясен әле берәүнең дә кире какканы юк.

Проектның музыкаль җитәкчесе – Россиянең халыкара югарылыкта танылган музыканты, трубач Вадим Эйленкриг. Концерт дәвамында маэстро, уйнаучы тренер кебек, үзенең җыйнак кына джаз-оркестры составында сәхнәдә иде. Гаҗәеп джазмен күп кенә җырга трубада уйнап торуы өстенә, үз номерын да тәкъдим итте (Салих Сәйдәшевнең «Әдрән диңгез» җыры темасына парафраз) – алдыбызда иң югары дәрәҗәдәге профессионал булуына шунда тагын бер кат инандык.

Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры оркестрының кыллы төркеме һәм валторначылары Мәскәүдән килгән хезмәттәшләре белән бергә эшләп китә алганнар (бу Казан башкару мәктәбенең югары дәрәҗәсен раслый). Театр оркестрантлары Эйленкриг музыкантлары белән берлектә тулы форматлы эстрада-симфоник оркестры («симфо-джаз» дияргә мөмкин) булдыра алганнар, ә бит республикада бу форматның булмавы үзен сиздерә.

Фестиваль концертларында оркестр белән саундтреклар авторы Станислав Курбацкий (Мәскәү) дирижерлык итте. Мондый состав куллану – нәтиҗәле чишелеш. Бу стиль җитезлегенә ия җанлы оркестр белән эшләүнең оптималь варианты. Монда да тарих белән сөйләшү идеясе чагыла. Нәкъ менә Казан кырыгынчы еллар ахырында илебезнең «джаз башкаласына» әверелә –

должна оставаться живой традицией и в XXI веке. Для тех, кто получает знания о музыке не от педагогов, а из современного звукового пространства, нужно чтобы классика была в «эфире» и, желательно, в современном исполнении и качественной записи. Просветительскую, воспитательную и объединяющую функцию искусства никто не отменял.

Музыкальный руководитель проекта – выдающийся российский музыкант международного уровня, трубач Вадим Эйленкриг. Весь концерт маэстро был на сцене в составе своего компактного джаз-оркестра как играющий тренер. Блестящий джазмен исполнял соло на трубе в аккомпанементе многих песен, феерично выступил с блестящим сольным номером (парафраз на тему песни Салиха Сайдашева «Адриатическое море»), и все могли лично убедиться, с каким высококлассным профессионалом мы имеем дело.

С московскими коллегами прекрасно сработалась струнная группа и валторнисты из оркестра ТАГТОБ им. М. Джалиля (подтвердив высокий уровень казанской исполнительской школы). Оркестранты театра вместе с музыкантами Эйленкрига образовали полноформатный эстрадно-симфонический оркестр (можно сказать «симфо-джаз»), которого нам, по большому счету, сейчас в республике не хватает. Управлял оркестром на концертах фестиваля дирижер и автор саундтреков Станислав Курбацкий (Москва). Задействовать такой состав – эффективное решение. Это оптимальный вариант живого оркестрового сопровождения, обладающего стилевой мобильностью. Идея диалога с историей проявилась и здесь. Ведь именно Казань в конце 1940-х годов стала «джазовой столицей» страны, когда в нашем городе обосновался прибывший из Китая джаз-оркестр Олега





Кытайдан кайткан Олег Лундстрем (1916-2005) джаз-оркестры бирелдә төпләнеп кала. Шәһәрдә чын «җанлы» джаз булуына Казанга килеп чыккан мәскәүләләр дә гаҗәпләнә торган булган. Лундстрем Мәскәүгә китә, әмма джаз традицияләре сакланып кала, А. Ключарев, Н. Җиһанов, Р. Яхин, А. Монасыйпов, Р. Белялов һәм башкаларда джаз интонацияләре һәм гармониясе чагылыш таба.

Виртуоз традицион татар баяны белән симфо-джазның «фолк-микстьы» бик үзенчәлекле, шул ук вакытта табигый яңгырады. Хәер, киң таралган world music юнәлеше кысаларында бу бик гадәти – бүгенге мәдәниятара коммуникацияләрдә дөнья халыкларының традицион инструментлары үз мөмкинлекләрен күрсәтә. Ә татар традицион инструментлары катнашында җанлы яңгыраш форматында моннан да уңышлырагын ишеткәнем юк иде әле…

Режиссер Юрий Александров үзенең элеккерәк булган хезмәтләре аша яхшы таныш, ул үз эшенең халыкара югарылыктагы остасы. Аның моңарчы бөтенләй таныш булмаган материалны ничек шәрехләячәге кызыклы иде… Күпчелек номерларда куючы режиссерның эше таң калдырды. Нәкъ менә шаблон куелыш, минемчә, музыка да, вокал да түгел, бүгенгәчә татар эстрадасының иң зәгыйфь урыны булып тора. Дөрес, бу юнәлештә хәрәкәт сизелә башлады кебек, әмма әлегә ул татар аудиториясенең билгеле бер өлешеннән ерак китеп уңыш казанырлык дәрәҗәдә түгел иде. Димәк, «конвертацияләнә торган» формат табылмаган иде әле.


Александровның иң зур казанышы – төрле стильдәге һәм эчтәлектәге 28 номердан «бер сулышта» кабул ителә торган концерт ясау, күтәрелеш һәм төшү ритмнары

Лундстрема (1916-2005). По свидетельству современников, приезжавшие в Казань москвичи удивлялись, что в городе есть «живой» джаз. Лундстрем уехал в Москву, но джазовые традиции остались, их влияние проявилось в джазовых интонациях и в гармонии у А. Ключарева, Н. Жиганова, Р. Яхина, А. Монасыпова, Р. Белялова и др.

Оригинально и при этом органично звучал «фолк-микст» виртуозного традиционного татарского баяна и симфо-джаза. Впрочем, в рамках широко распространенного направления world music это обычная вещь – традиционные инструменты народов мира показывают свои возможности современной межкультурной коммуникации. Но вот с участием татарских традиционных инструментов ничего более удачного в таком формате живого звучания мне слышать не приходилось…

Режиссер Юрий Александров широко известен своими работами прошлых лет, это крупный мастер своего дела международного уровня. Было интересно, как он будет трактовать изначально незнакомый для себя материал…
В подавляющем же большинстве номеров работа режиссера-постановщика вызвала восхищение. Именно шаблонная постановка, а не музыка и не вокал, на мой взгляд, до сих пор остается самым слабым местом татарской эстрады. Хотя какие-то намерения двигаться в этом направлении уже появлялись, но их результаты не позволяли рассчитывать на успех за пределами определенной части татарской аудитории. А значит «конвертируемый» формат у нас ранее найден не был. Главное же достижение Александрова в создании идущего «на едином дыхании» концерта из 28 разных по стилю и содержанию номеров, создание «песенного спектакля»








белән, тезелгән драматургиясе белән «җыр спектакле» тудыру. Моннан тыш, бу алга таба сәхнәдә, телевидениедә һәм башка прокат өчен уңайлы кабатланмалы шоу, аның һәр кисәге аерым-аерым да яши ала, кирәк чагында төрле блокларга да берләштерелә ала.

Сәнгатьтә һәр яңа күренеш алдарак булган әсәрләрдән яки проектлардан кечерәк кенә булса да үзгәлекне күздә тота. Шул ук вакытта ул алдарак булган әсәрләр һәм проектлар белән генетик бәйләнештә, хәтта аларны кире каккан очракта да. Бу сәнгатьнең яшәү һәм үсеш законы... Сәнгатьтә яңалыкка шикләнеп караучыларны аңларга була. Татар халкының тарихи хәтере бу. «Минем» гадәти сәнгатем урынына миңа ошамаган ниндидер башка әйбер тагарга җыеналар дигән ихлас курку юк урында барлыкка килми. Алай гына да түгел, тарихи хәтер бу куркуны «миннән тартып алырга мөмкиннәр!» дәрәҗәсенә җиткереп тагын да арттыра. Без моны баштан кичердек инде. Мәсәлән, 1917 ел татар мәдәниятен кисеп алды, аның мөселман катламын дистәләрчә елларга томалап куйды.

Хәзер безгә бу хәвеф янамый һәм «бер кнопкалы телевизор» да юк. Традицияләрнең уңышлы торгызылуын күреп, үсеш турында сөйләшергә дә була. «Үзгәреш җиле» фестивале – сәнгатьтә татарның уңышлылыгын яңартуның ачык мисалы. Сәнгатьтәге яңалык күптән инде искене кысрыклап чыгармый, алар бергә бик матур яшиләр. Бөтен кеше өчен сәнгать бар ул – никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшырак.

с продуманным ритмом подъемов и спадов, с выстроенной драматургией. Кроме того, это удобное для последующего сценического, телевизионного и другого проката циклическое шоу, все части которого могут существовать по отдельности, а по необходимости монтироваться в определенные блоки.

Любое новое явление в искусстве подразумевает хоть маленькое, но отличие от предшествовавших произведений или проектов. И одновременно оно имеет генетическую связь со всеми предшествовавшими произведениями и проектами, даже если оно декларирует их отрицание. Это закон существования и развития искусства... Тех, кто действительно опасается появления нового в искусстве, можно понять. Такова историческая память татарского народа. Искренние опасения, что вместо «моего» привычного искусства собираются подсунуть какое-то другое, которое мне не нравится, возникают не на пустом месте. Более того, исторической памятью это опасение усиливается до уровня «мое могут отнять!» И так уже бывало. Например, 1917 год словно разрезал татарскую культуру, заблокировал на десятилетия весь ее мусульманский пласт.

Сейчас такой угрозы нет и «однокнопочного телевизора» нет. Более того, идет восстановление традиции, идет так успешно, что уже можно говорить о развитии. Фестиваль «Узгэреш жиле» – яркий пример возрождения татарской успешности в искусстве. Новое в искусстве уже давно не вытесняет старое, а прекрасно сосуществует с ним. Есть искусство для всех – и чем его будет больше, тем лучше.

## ГҮЗӘЛ СӘЙФУЛЛИНА

Сәнгать фәннәре кандидаты,
ТР атказанган сәнгать эшлеклесе
*«Реальное время»*

Бер елдан артык эш, эзләнүләр, кызу бәхәсләр, төрлечә сынаулар, репетицияләр… Уйлаганны сәхнәгә күчерә башлаганчы нияте үк битараф калдырмаган концерт программасы тәкъдим ителгән нибары өч кич… «Үзгәреш җиле» – «Ветер перемен» – 5-6 ноябрьдә Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә үткән, 4 декабрьдә Мәскәү премьерасы күтелгән татар җыры фестиваль шулай дип атала.*

Татар эстрада мәдәниятендә килеп туган вазгыятькә чакыру ташлаган проект өчен моннан да уңышлы исем була алыр идеме икән?! Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның татар эстрадасының халәте һәм үзгәреш кирәклеге турында искәртеп куюы этәргеч ясады. Ә бит аның сүзләрендә күпләрнең күптән уйлаганы чагылыш тапкан иде…

Фестивальнең үзенчәлеге нидә? Иң мөһиме – татар җырының күнегелгән стереотиплардан арынып, яңача яңгырашы. Проектның концепциясендә көтелмәгән әйберләр шактый, әмма авазлар дөньясын ныграк тойган саен, аның бик уйланылган булуына төшенә барасың. Биредә жанрлар өстенлеге юк: программага җырның төрлесе җыелган – авторлар әсәрләре һәм фольклор да, элеккегеләр дә, заманчалары да.

* *«Үзгәреш җиле» фестивале беренче тапкыр 2016 елның 5-6 ноябрендә Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә үтте, 2016 елның 4 декабрендә проект Мәскәүдә тәкъдим ителде. Проект турында массакүләм матбугат чараларында басылган язмаларның (рецензияләр) өзекләре матбугатка күзәтү рәвешендә бирелә.*

## ГУЗЕЛЬ САЙФУЛЛИНА

Кандидат искусствоведения,
заслуженный деятель искусств РТ
*«Реальное время»*

Больше года работы, поисков, жарких споров, проб, репетиций… И всего три вечера с концертной программой, сам замысел которой, похоже, мало кого оставлял равнодушным еще задолго до ее реализации на сцене. «Үзгәреш җиле» – «Ветер перемен» – так называется фестиваль татарской песни, прошедший 5 и 6 ноября в театре оперы и балета им. М. Джалиля в Казани и ожидающий премьеры в Москве 4 декабря.*

Название как нельзя более удачное для проекта, задуманного как некий вызов ситуации, сложившейся в современной татарской эстрадной культуре. Толчком к его появлению стало критическое замечание Президента Республики Татарстан Р.Н. Минниханова о состоянии татарской эстрады и необходимости изменений здесь. Но в замечании этом отразилось то, о чем думалось давно и многим…

В чем особенности фестиваля? Главное – татарская песня в новом, уходящем от привычных стереотипов, звучании. В самой концепции проекта много неожиданного, но, как понимаешь по мере погружения в этот звуковой мир, хорошо продуманного. Здесь нет жанровых предпочтений: в программе собраны песни разные — авторские и фольклорные, прошлых лет и современные. Общее, что

* *Впервые фестиваль «Узгэреш жиле» состоялся 5-6 ноября 2016 года на сцене ТАГТОиБ им.М.Джалиля, 4 декабря 2016 года проект был представлен в Москве. Отзывы о проекте в средствах массовой информации (рецензии) приводятся фрагментарно (цитаты, выдержки) и представляют собой обзор печати.*

Аларны татар эстрадасы репертуарының алтын фондына кергән булулары гына берләштерә. Аранжировкада да, сәхнә бизәлешендә дә, костюмнарда да этника ассызыкланмаган. Башкаручылар таныш популяр мелодия белән яңача эшләүгә корылган гадәти булмаган шартларга куелган.

Проектка катнашучылар да төп идеягә карап сайланган, үзәктә – үзләрен көтелмәгән яктан күрсәтә алган яшь җырчылар. Алар – республика, бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреатлары, үзләрен төрле яссылыкта күрсәтә алган музыкантлар, иң мөһиме – татар көе һәм теленең матурлыгын тоемлый алучылар, шул ук вакытта – яңа иҗади тәҗрибә өчен ачык булучылар (алар белән һәм, гомумән, проектның барлык катнашучылары белән затлы буклет аша танышу мөмкинлеге дә бар, театр холлында фотогалерея да ясалган).

«Үзгәреш җиле» кебек музыкаль шоуны ясаучылар – В.Эйленкриг (проектның музыкаль җитәкчесе, Мәскәү), Ю.Александров (режиссер, Санкт-Петербург), алар белән «бер дулкында» уйлаучы рәссам В.Герасименко (Мәскәү) һәм И.Виноградов (ут, Мәскәү), дирижер С.Курбацкий (Мәскәү), шулай ук, яңа аранжировкаларның билгесез булып калганган авторлары –башкаручыларда нәкъ менә шушы сыйфатларның ярашуына таянганнар. Дөньякүләм тәҗрибәсе булган музыкаль сәхнә эшлеклеләренең катнашуы, сүз дә юк, проектны баетты һәм планкасын да күтәрде: Юрий Александров – бүгенге көндә иң авторитетлы музыка һәм театр режиссерларының берсе, Вадим Эйленкриг – күпьяклы эшчәнлеге белән профессионаллар арасында да, киң аудиториядә дә авторитет яулый алган музыкант. Аның проектта катнашуы

их объединяет – это то, что все они входят в золотой фонд репертуара, исполняемого на татарской эстраде. Ни в аранжировках, ни в оформлении сцены, ни в костюмах нет подчеркнутой этничности. Исполнители поставлены в непростые для них условия работы в стилистике по-новому услышанных популярных мелодий.

Замысел определил и состав участников проекта, в центре которого оказались певцы — молодые, но уже ярко и неординарно заявившие о себе. Это лауреаты республиканских, российских и международных конкурсов, музыканты, активно проявляющие себя в разных ипостасях, но, что важнее всего, — прекрасно чувствующие природу, красоту татарского мелоса и языка и, одновременно, — открытые к новым творческим опытам. (Поближе познакомиться с ними, как и со всеми участниками проекта, позволяет информативно емкий, красиво оформленный буклет, а также фотогалерея в холле театра).

Именно на сочетание этих качеств опирались главные создатели яркого музыкального шоу, каким предстал «Ветер перемен»: В.Эйленкриг (музыкальный руководитель проекта, Москва), Ю.Александров (режиссер, Санкт-Петербург), мыслящие «в унисон» с ними художники В.Герасименко (Москва) и И.Виноградов (свет, Москва), дирижер С.Курбацкий (Москва), а также, к сожалению, оставшиеся неизвестными авторы новых аранжировок. Участие деятелей музыкальной сцены с мировым опытом обогатило и безусловно приподняло планку проекта: Юрий Александров – сегодня один из авторитетнейших музыкально-театральных режиссеров, Вадим Эйленкриг – музыкант, благодаря своей







(музыкаль җитәкче буларак «авазлар партитурасын» төзүе белән генә түгел, үз солистлары белән балкыган джаз оркестры лидеры буларак та, яхшы трубач буларак та) фестивальнең музыкаль имиджын билгеләде.

Проектта югары класслы профессионалларның катнашуы концертның вак детальләренә кадәр сыйфатлы булуын тәэмин итә алды. Үзәгенә әле чатырга, әле бөредән атып килгән чәчәккә әверелүче, утның һәм төснең уены тәэсирендә берләштерүче визуаль элемент буларак хезмәт иткән конструкция куелган сәхнә дә уңышлы табыш. Программаның тагын бер берләштерүче билгесе һәм музыкаль символы – таныш көй – А.Ключаревның «Туган җирем – Татарстан» җыры, концертның бүлекләре шушы таныш авазлар белән ачылды һәм финалда да катнашучылар шушы җырны башкарды. Программаның алып баручылары да отышлы сайланган иде – сөйкемле Марина Ясельская һәм таланты белән дә, юмор хисе белән таң калдыра торган Равил Шәрәфиев. Тамашачыны җыр «дулкынына» көйли торган, шул ук вакытта үткен дә булган, таблода тәрҗемәсе язылып барган (бу опера театрының тәртибе) татарча текстлар – мондый кичәләр өчен кулай вариант.

Тулаем алганда, «Үзгәреш җиле» программасы Татарстан заллары өчен гадәти булган эстрада концерты кысаларыннан чыгып, уңышлы режиссуралы, әлеге жанрның дөньякүләм тәҗрибәсе кулланыла торган музыкаль шоуга әверелгән иде. Заманча музыка сәхнәсендә һәр җырның стилистик үзенчәлеге табылган – джаз яратучылар үз теләгәннәрен ишетә ала, мюзиклга мөкиббәннәр – үзләренекен; аерым номерларга рэп һәм брейк данс

многосторонней деятельности завоевавший авторитет как среди профессионалов, так и у широкой аудитории. Его присутствие в проекте (не только как музыкального руководителя, выстраивавшего его «звуковую партитуру», но и как лидера джазового оркестра, блеснувшего своими солистами, и как великолепного трубача) во многом определило весь музыкальный имидж фестиваля.

Участие в проекте профессионалов высокого класса обеспечило качество всех «слагаемых» концерта, вплоть до деталей. Удачей можно назвать организацию пространства на сцене, в центре которой находится лаконичная конструкция, превращающаяся то в шатер, то в раскрывающийся цветок, но при любых играх света и цвета всегда служащая объединяющим визуальным элементом. Аналогичным звуковым объединяющим знаком и музыкальным символом программы стала знаменитая мелодия А.Ключарева «Туган җирем Татарстан», своими «позывными» открывающая каждое отделение концерта и исполняемая всеми участниками в финале. Безусловно выиграла программа благодаря ведущим – обаятельной Мариной Ясельской и всегда восхищающим своим талантом и юмором Равилем Шарафеевым. Остроумные и, одновременно, точно настраивающие слушателя на «тональность» песни тексты на татарском языке, с параллельным переводом на табло (что давно уже норма в оперном театре) – кажется, оптимальный вариант для вечера такого рода.

В целом, вся программа «Үзгәреш җиле» переросла рамки привычного для залов Татарстана эстрадного концерта и предстала как эффектно срежиссированное музыкальное шоу, вобравшее многое из мирового опыта этого жанра. Установка на стилистическое разнообразие отразилась в языке, которым «говорит» песня на







элементлары да табигый үрелеп киткән. Җырчылар сәхнәдә музыкантлар белән дә, «Дорога из города» бию театры артистлары белән дә бәйләнештә иде – аларның булуы тамашаны тагын да җанландырды. Теге яки бу номер уңышының әһәмиятле факторы булып – башкаручы талантыннан тыш – көйнең асылына үтеп керә, аны яңача ача алган аранжировка тора һәм бу үзенчәлекле сәхнә чишелешенә китергән.

Халык яраткан таныш җырларның яңача укылышы мәсьәләсе, һичшиксез, «Үзгәреш җиле» фестивалендә тәкъдим ителгән программа куйган төп сорауларның берсе. (Гадәти булмау һәрвакыт бәхәс уята!). Әмма гадәт ул әле традиция түгел һәм эстетиканы бәяләү билгесе була аламы икән? Татар музыка мәдәнияте дистәләрчә еллар җитди үзгәрешләр җиленә карап яши. Аның үсеш дәлиле – иҗади сайлау иреге һәм теләсә нинди мәсьәләнең профессиональ чишелешенә омтылыш. «Үзгәреш җиле» проектының үзәгендә торган кеше – Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры директоры, фестивальнең генераль продюсеры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов шуларны күздә тоткандыр. Академик традицияләрне һәм татар музыкасын эчтән белгән, шоу-бизнес законнарын өйрәнеп, Муса Җәлил исемендәге театрны югары классլы музыка-театр коллективы буларак Европага таныта алган менеджер, татар җырының алтын фондын сакларга ярдәм иткән һәм шул ук вакытта аның бүгенге интерпретация мөмкинлекләрен күрсәтә алган проект оештырды.

современной музыкальной сцене: любители джаза здесь услышат свое, поклонники традиций мюзикла – свое; на удивление органично вписывались в отдельные номера элементы рэпа и брейк-данса и пр. Певцы часто находились «в диалоге» с солистами-инструменталистами, с артистами театра танца «Дорога из города», чье присутствие на сцене делало номера более зрелищными и динамичными.

Важнейшим фактором успеха того или иного номера – помимо собственно таланта исполнителя — стала аранжировка, «высвечивающая» суть мелодии, преображающая ее, или, порой, — наделяющая ее новым характером, что, соответственно, вело к необходимости особого сценического решения.

Вопрос непривычного, «иного» прочтения хорошо известных и любимых в народе песен, безусловно, — один из главных при осмыслении программы, представленной в фестивале «Үзгәреш җиле». (Ведь у нас непривычное – часто осуждаемое!). Но привычка – еще не традиция и вряд ли эстетический критерий. Татарская музыкальная культура живет под ветром серьезных перемен уже много десятилетий. Залог ее успешного развития – в свободе творческого выбора и в профессиональном подходе к решению любых задач. Кажется, именно это имел в виду человек, оказавшийся в центре проекта «Үзгәреш җиле», — генеральный продюсер фестиваля, директор ТГАТОБ им. М.Джалиля Рауфаль Мухаметзянов. Знающий и академическую традицию и татарскую музыку изнутри, посвященный в законы шоу-бизнеса, менеджер, благодаря которому театр им. Джалиля давно известен в Европе как музыкально-театральный коллектив высокого класса, он организовал проект, способствующий сохранению золотого фонда татарской песни, и одновременно, показавший многообразие возможностей ее интерпретаций сегодня.



## ИЛДАР ХАРИСОВ

***«События недели»***

Татар җыры ничек җырланырга тиеш? Хәер, гомумән, мондый сорау куярга ярыймы икән әле – хәзерге эстетик фикер төрлелеге заманында. Һәр башкаручының үз идеалына табу баруы үз иркендә, һәр тыңлаучы булганы арасыннан үзенә якынын сайлап ала…

Уңайлы кысаларыбыздан чыгып, музыка өлкәсендә – популяр эстрада музыкасында – татар мәдәнияте дөньяга нәрсә тәкъдим итә ала, дип үз алдыбызга сорау куйсак, бүгенге татар эстрадасының хәле шәптән түгеллеген танырга туры киләчәк. Җырчыларыбызның тавышы белән горурлана алабыз, аерым композиторларның таланты белән, әмма бүгенге татар эстрадасында дөнья бәяләрлек бербөтен «продуктыбызны» табармын димә – көндез чыра яндырып эзләсәң дә юк ул.

Шуңа күрә татар эстрадасы өчен җаваплылык тоючыларның, беренчедән, шундый «продукт» табу омтылышын, икенчедән, заман белән бергә атлаган татар популяр музыкасы үсеше өчен база булдыру теләген аңлап була.

«Үзгәреш җиле» («Ветер перемен») фестивале бу юлда ныклы адым булып тора. Яшь җырчылар башкаруындагы данлыклы татар «моңы» яңача эшкәртелгән, ә әлеге яңа эшкәртүләр дөньяның джаз, рок-н-ролл, мюзикл, кантри кебек популяр музыкасы тарихына ихтирам һәм елмаю белән өртелгән иде. Бу стильләр татар музыкасына элегрәк тә ят түгел иде, әмма бу очракта аранжировканың да, җанлы башкаруның да сыйфаты роль уйнады. Алинә Шәрипҗанова башкаруында «Гөлҗамал» җыры шулкадәр

## ИЛЬДАР ХАРИСОВ

***«События недели»***

Как должна исполняться татарская песня? Впрочем, можно ли вообще так ставить вопрос – в наши дни, время эстетического плюрализма? Казалось бы, каждый исполнитель волен следовать своему идеалу, а каждый слушатель – выбирать из имеющегося в наличии то, что ближе и приятнее его слуху и сердцу…

Как только мы выйдем за уютные рамки плюрализма и спросим себя, что татарская культура может предложить миру в самой востребованной ныне музыкальной области – в музыке популярной, эстрадной, то придется признать, что в качественном плане современная татарская эстрада находится в плачевном состоянии. Можно гордиться голосами певцов, одаренностью отдельных композиторов, но цельного продукта, который мог бы «котироваться» на мировом уровне, в современной татарской эстраде нужно искать днем с огнем.

Понятно поэтому желание тех, кто чувствует ответственность за татарскую эстраду, во-первых, способствовать созданию такого продукта, а во-вторых, заложить базу для развития татарской популярной музыки, которое бы шло в ногу со временем.

Фестиваль «Үзгәреш җиле» («Ветер перемен») представляется важным шагом на этом пути. Знаменитый татарский «моң» в исполнении молодых певцов сочетался с блестящими обработками, в которых был слышен то подчеркнуто уважительный, то ироничный диалог с историей мировой популярной музыки: джаз, рок-н-ролл, мюзикл, кантри… Эти стили были не чужды татарской музыке и раньше, но здесь сыграло роль качество

дулкынландыргыч яңгырады – «Уитни Хьюстонга безнең җавап» диярсең; Илгиз Шәйхразиев «Бөрлегән»не башкарып бу җырның диско-потенциалын ачты – Вадим Эйленкриг трубасы чакыруына «рэп» җавап бирде; ә Язилә Мөхәммәтова белән виртуоз баянчы Айдар Гайнуллинның ягымлы «әңгәмәсе» нигезендә «Умырзая» нәзакәтле «соул» булып чәчәк атты. Аларның теләсә кайсын һәм фестивальнең башка бик күп композицияләрен курыкмыйча «Евровидение» популяр җыр конкурсында тәкъдим итергә була: Татарстан болай эшкәртелгән җырлар белән кызарырга туры килмәячәк.

Программаның музыкаль йөзенә аның төсле-утлы чишелеше дә туры килеп тора иде: һәр җыр үзенә килешкән, текстка ятышып торган яисә җырга эмоциональ контрапункт булдырган һәм сәхнә үзәгендәге төп декоратив элемент булган гөмбәз-тюльпанның эчендә дә, тышында да ут уйнатып фантазияне уяткан төсләр һәм визуаль образлар җыелмасын алган. Җырчы һәм биючеләрнең («Дорога из города» бию театры) үзенчәлекле костюмнарын да, барлык катнашучыларның стилистик яктан тотрыклы пластикасын искәртеп узам – фестиваль тыңлау рәхәте белән генә чикләндермичә, күзләргә дә ямь бирде.

«Үзгәреш җиле» планканы югары куйды – җырларның аранжировкасына һәм башкарылуына профессиональ караш планкасын гына түгел, бербөтен аудио-музыкаль номер тудыру планкасын да, шул номерларны берләштергән шоу ясау планкасын да… Җәһәтрәк ис, «Үзгәреш җиле»!

как аранжировок, так и живого исполнения. С какой волнительной свежестью прозвучала легендарная народная песня «Гульджамал» в исполнении Алины Шарипжановой – «наш ответ Уитни Хьюстон»; какой зажигательный диско-потенциал открылся в «Бөрлегән» («Костянике») с Ильгизом Шайхразиевым, артистичный «рэп» которого принял «вызов» трубы Вадима Эйленкрига; каким изысканным «соул» расцвел «Подснежник» на стихи А. Файзи в нежнейшей «беседе» Язили Мухаметовой и виртуоза баяна Айдара Гайнуллина! Любую из этих и многие другие композиции фестиваля можно смело представить на международном конкурсе популярной песни «Евровидение»: с такими обработками Татарстан не ударит в грязь лицом.

Под стать музыкальному облику было цвето-световое решение программы: каждая песня получила индивидуальный выбор красок и визуальных образов, порой прямо вытекающих из текста, но чаще создающих к нему эмоциональный контрапункт и будящих фантазию игрой линий, пятен, пульсацией потоков света над и внутри движущихся лепестков купола-тюльпана – основного декоративного элемента в центре сцены. Упомяну также оригинальные костюмы певцов и танцоров (казанский театр танца «Группа из города») и непринужденную, но всегда стилистически выдержанную пластику всех участников действа – фестиваль стал праздником не только для слуха, но и для глаза.

«Ветер перемен» задал высокую планку – планку современного профессионального подхода не только к аранжировке и исполнению песни, но и к созданию цельного аудио-музыкального номера, а также продуманного во всех деталях шоу из таких номеров… Жарче дуй, «Үзгәреш җиле»!

# КАТНАШУЧЫЛАР
# УЧАСТНИКИ

# JUKEBOX TRIO



**Музыкаль төркемдә катнашучылар:**
ВЛАДИМИР ИВАНОВ
ИЛЬЯ ИВАНОВ
ГАРРИ КРАУЛИС

**Карьерасы:**
«Jukebox trio»ның талантын һәм үзенчәлекле иҗатын беренчеләрдән булып «Яңа дулкын» фестивалендә Алла Пугачева бәяләгән иде. Алга таба музыкантлар «Comedy club» проектында катнаштылар, «Главная сцена» («Россия 1» телеканалы) шоусының финалына чыктылар, Иван Ургантның «Подмосковные вечера» (Беренче канал) тапшыруының музыкаль бизәлешен тәэмин иттеләр. «Jukebox trio» Элтон Джон, Брайан Адамс, AEROSMITH һәм башка дөньякүләм танылган йолдызларның концертларын башлап җибәрде; Бобби МакФеррин, Джон Ньюман, Nouvelle Vogue музыкаль төркеме белән бер сәхнәдә чыгышлар ясады. Коллектив гастрольләргә күп йөри. Музыкаль төркем Сочида Олимпиада уеннары ачылу тантанасында катнашты; Казанда узган дөньякүләм спорт чараларының Мәдәни программасын бизәде: Универсиада программасында (2013) һәм Су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты ачылу һәм ябылу тантаналарында чыгыш ясады (2015). «Элвин и бурундуки» мультфильмы геройлары да алар тавышы белән сөйләшә (1 һәм 4 сезон). Музыкаль төркемнең җырлары һәм клиплары илнең музыка телеканалларында һәм радиостанцияләрендә еш әйләндерелә.

**Казанышлары, мактаулы исемнәре:**
«Яңа дулкын» конкурсында Алла Пугачеваның махсус призы (2006); Казан шәһәренең яшьләр мәдәнияте үсешенә өлеш керткән өчен Почет грамотасы (2006); «Jukebox trio» – «Универсиада-2013 илчесе»; Студентлар спорты үсешенә һәм популярлаштыруга өлеш керткән һәм 2013 елда XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасы идеяләрен алга этәргән өчен Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Рәхмәте; «Вне формата» номинациясе буенча «Musicbox» премиясе (2017).

**Репертуары:**
Музыкаль төркем таныш җырларны да, рус һәм инглиз телләрендә язылган үз җырларын да битбокс техникасын *a capella* белән кушып, үзенчәлекле манерада башкара.

## JUKEBOX TRIO

**Участники:**
ВЛАДИМИР ИВАНОВ
ИЛЬЯ ИВАНОВ
ГАРРИ КРАУЛИС

**Карьера:**
Впервые талант и индивидуальность «Jukebox trio» отметила Алла Пугачева на фестивале «Новая Волна». В дальнейшем музыканты участвовали в проектах «Comedy club», стали финалистами шоу «Главная сцена» (телеканал «Россия 1»), отвечали за музыкальное оформление шоу Ивана Урганта «Подмосковные вечера» (Первый канал).
«Jukebox trio» много гастролируют, открывали концерты Элтона Джона, Брайана Адамса, AEROSMITH, делили сцену с Бобби МакФеррином, Джоном Ньюманом, Nouvelle Vague и др. Группа стала участником культурной программы Универсиады в Казани (2013) и церемонии открытия МОК на Олимпиаде в Сочи с участием первых лиц государства (2014), а также выступила на Церемонии открытия и закрытия Чемпионата мира по водным видам спорта в Казани (2015). Музыканты группы озвучили мультфильм «Элвин и бурундуки» (1 и 4 сезоны). Песни и клипы группы находятся в ротации радиостанций и музыкальных телеканалов страны.

**Награды, достижения:**
Специальный приз Аллы Пугачевой на конкурсе «Новая волна» (2006). Почетная грамота за вклад в развитие молодежной культуры города Казани (2006). «Jukebox trio» – «Посол Универсиады 2013». Благодарность Президента Республики Татарстан Р.Н.Минниханова за вклад в популяризацию и развитие студенческого спорта и продвижение идей XXVII Всемирной летней Универсиады 2013 года в городе Казани, Грамота за вклад в подготовку и проведение XXVII Всемирной летней Универсиады 2013. Награда Премии «Musicbox» в номинации «Вне формата» (2017).

**Репертуар:**
Вокальная команда совмещает техники битбокс и *a capella*, исполняя как известные песни в необычной манере, так и авторский материал на русском и английском языках.

# LUCY CAMPETI




Доминикан чыгышлы итальян җырчысы, пианистка һәм педагог.

**Карьерасы:**
Соло– һәм бэк-вокалистка сыйфатында бик күп танылган артистлар белән хезмәттәшлек иткән. Jimmy Holden, King James Johnson, Herbie Goins, Martha High (James Brown), Ricky Bailey (Delegation), Maestro Franco Micalizzi, James Taylor, Renato Zero, Laura Pausini һәм башка бик күпләр белән гастрольләргә чыккан һәм студияләрдә язылган. Италиядә актриса буларак та яхшы билгеле: «The Sisters, La via del successo» һәм «Me and Bessie Smith» мюзиклларында төп рольләрне башкарган, «Volutta» һәм «Beyond Reality Project-Electromusical» шоуларының музыка авторы. «Gabin» төркеме белән хезмәттәшлек итеп дөнья күләмендә танылa. «Burning Souls» госпел-квартеты һәм «Lucy Soul Band» төркеме лидеры.

## LUCY CAMPETI

Итальянская певица доминиканского происхождения, пианистка и педагог.

**Карьера:**
На протяжении карьеры сотрудничала с множеством известных артистов в качестве соло– и бэк-вокалистки. Гастролировала и участвовала в студийных записях с Jimmy Holden, King James Johnson, Herbie Goins, Martha High (James Brown), Ricky Bailey (Delegation), Maestro Franco Micalizzi, James Taylor, Renato Zero, Laura Pausini и многими другими. Известна в Италии как прекрасная актриса, исполнительница главных ролей в мюзиклах «The Sisters, La via del successo» и «Me and Bessie Smith», а также автор музыки для шоу «Volutta» и «Beyond Reality Project-Electromusical».
Мировую известность Люси получила благодаря сотрудничеству с группой «Gabin», известной танцевальными диско-джазовыми хитами и коллаборациями с мировыми звездами – Chris Cornell, Dee Dee Bridgewater, Flora Purim, Z Star и другими. Является лидером госпел-квартета «Burning Souls» и группы «Lucy Soul Band».

# ӘМИР ӘХМӘДИШИН



Түбән Камада туган.

**Белеме:**
Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, музыка сәнгате факультеты, ялгыз җырлау кафедрасы, РФ һәм ТР халык артисты, профессор В.Ә.Ганиева классы; Казан федераль университеты (Икътисад һәм финанслар институты).

**Казанышлары, мактаулы исемнәре:**
Р.Вәһапов исемендәге Халыкара татар җыры конкурсы (2015), «Созвездие-Йолдызлык», «Студент язы» республика фестивальләре лауреаты.

**Карьерасы:**
2017 елдан — Казан шәһәре филармониясе солисты («Казан» милли-мәдәни үзәге).
Эстрадада чыгыш ясый, Казанда һәм Татарстан Республикасында үткәрелгән зур чараларда җырлары белән катнаша (Универсиада-2013, FINA-2015, WorldSkills-2016 һәм башкалар).

**Репертуары:**
Татар халык һәм татар эстрадасы җырлары. Рус, инглиз, итальян телләрендә популяр һәм классик җырлар.

## АМИР АХМАДИШИН

Родился в Нижнекамске.

**Образование:**
Казанский государственный университет культуры и искусств, факультет музыкального искусства, кафедра сольного пения, класс народной артистки РФ и РТ, профессора В.А.Ганеевой; Казанский федеральный университет (Институт экономики и финансов).

**Награды, достижения:**
Победитель Международного конкурса татарской песни им. Р. Вагапова (2015), лауреат фестиваля «Созвездие-Йолдызлык», республиканской «Студенческой весны».

**Карьера:**
С 2017 года — солист Казанской городской филармонии (НКЦ «Казань»).
Выступает на эстраде, принимает участие в крупных мероприятиях г. Казани и Республики Татарстан (Универсиада-2013, FINA-2015, WorldSkills-2016 и др.).

**Репертуар:**
